КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1050

Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Рес-

публикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 26 ноябрь, 1050 нче
карары белән расланды

Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булып торган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә.

3. Субсидия бирү бу Тәртипнең 2 нче пунктында күздә тотылган максатлар өчен Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына (алга таба – Вәкаләтле орган) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия алу хокукына түбәндәге критерийларга җавап бирүче коммерциягә карамаган оешмалар ия:

субсидия алучы Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән һәм эшчәнлеген гамәлгә ашырган коммерциягә карамаган оешма булып тора;

субсидия алучының татар телен, фән, мәгариф, милли мәдәниятне, тарихи мирасны, халык педагогикасын, демографияне үстерү өлкәсендәге программаларны тормышка ашыруда тәҗрибәсе булырга тиеш;

субсидия алучы субсидия бирү турындагы килешүне төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килүче айның беренче көненә субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

субсидия алучы үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булмаска тиеш;

субсидия алучы чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булмаска тиеш;

субсидия алучы бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокук актлары нигезендә акча алучы булмаска тиеш;

субсидия алучының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняләр, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаска тиеш;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаска тиеш.

5. Субсидия алу өчен субсидия алучы Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

субсидия бирү турында гариза;

субсидия алучының гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелгән барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре;

субсидия алучының җитәкчесе вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләре;

субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган, субсидия алучыга карата үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процедураларының булмавы турындагы гарантияле хат;

субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган, бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауның, шулай ук субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычларының булмавы турындагы гарантияле хат;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмавын раслый торган документ;

штат расписаниесе;

субсидия алучының гариза бирү датасына кадәр килүче соңгы ике ел өчен татар телен, фән, мәгариф, милли мәдәниятне, тарихи мирасны, халык педагогикасын, демографияне үстерү өлкәсендәге программаларны тормышка ашыру буенча эшчәнлеге турында мәгълүмат;

субсидия алучы җитәкчесе тарафыннан расланган һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар сметасы.

Бу пунктның җиденче абзацы белән күздә тотылган документны коммерциягә карамаган оешма кертмәгән очракта, Вәкаләтле орган әлеге документны тиешле дәүләт хакимияте органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Кертелгән документларның күчермәләре субсидия алучының җитәкчесе тарафыннан раслана.

6. Теркәлгән документлар белән субсидия бирү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәүгә алу Вәкаләтле орган тарафыннан аларны тапшырган көннең икенче эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

7. Вәкаләтле орган субсидия бирү турындагы гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә аны карап тикшерә һәм субсидия бирү турындагы яисә субсидия бирүдән баш тарту турындагы боерык рәвешендә карар кабул итә.

Әгәр дә вәкаләтле орган бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы җиденче абзац белән күздә тотылган документны тиешле дәүләт хакимияте органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алса, документларны карап тикшерү һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү әлеге документ Вәкаләтле органга кергән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турындагы хәбәрнамә Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучыга тиешле карарны кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

8. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучының бу Тәртипнең 4 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

субсидия алучы бу Тәртипнең 5 нче пункты белән күздә тотылган документларны тапшырмау (тулысынча тапшырмау);

тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

бюджет йөкләмәләренең лимиты булмау;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чыгымнарга туры килмәү.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта, кабул ителгән карар нәтиҗәләре турындагы белдерүдә баш тартуның нигезләре күрсәтелә.

9. Субсидия бирү Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелгән субсидия бирү турындагы килешүгә таянып гамәлгә ашырыла.

Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнар төрләре;

субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең әһәмияте;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидияләрдән файдалану турында, шул исәптән субсидиядән файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирү вакытлары һәм формасы;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

субсидия алучының Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

югары технологияле чит ил җиһазларын, чималны һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасы субсидияләре акчасы исәбеннән сатып алуны тыю;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

10. Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = K \times (Z_1 + Z_2 + Z_3),$$

монда:

K – Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмасында белем алучы Кытай Халык Республикасыннан студентлар саны;

S – субсидия күләме, сум;

$Z_1$ – белем бирү хезмәтләре өчен чыгымнар, сум;

$Z_2$ – минималь академик стипендия күләмендә матди ярдәм күрсәтү өчен түләү чыгымнары, сум;

$Z_3$ – тулай торакта яшәү өчен чыгымнар, сум.

11. Субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткече – дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программала-ры, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан белем алган татар

диаспорасы вәкилләренең факттагы саны белән килешүдә күрсәтелгән Кытай Халык Республикасыннан белем алырга тиешле татар диаспорасы вәкилләре саны чагыштармасы.

12. Вәкаләтле орган килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә субсидия алучының кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына субсидия күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия алучы Вәкаләтле органга субсидиядән файдалану һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны килешү белән күздә тотылган вакытларда һәм форма буенча кертә.

14. Субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидиядән файдалану турындагы хисапны килешүдә билгеләнгән вакытта тапшырмаган;

Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс тикшерендә тоту органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган;

субсидия чараларын максатчан файдаланмаган;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешмәгән.

15. Бу Тәртипнең 14 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакыты субсидия алучы тарафыннан бозылган очракта, Вәкаләтле орган субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

16. Вәкаләтле орган һәм финанс тикшерүендә тоту органнары субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

17. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

18. Субсидия алучы тарафыннан Вәкаләтле органга тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучы җитәкчесенә йөкләнә.

19. Хисап финанс елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидия акчасы хисап финанс елыннан соң килүче финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемена Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләттерелергә тиеш.

_______________________________